# КАРАР

Татарстан Республикасы Яшел Үзән муниципаль районы Олы Карауҗа авыл җирлегенең Олы Карауҗа торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

2020 елның 8»декабре, № 3

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде, 2020 елның 5 декабрендә сәгать 17.00 минутта Яшел Үзән муниципаль районы Олы Карауҗа авыл җирлеге Олы Карауҗа торак пунктында узган 2021 елда , яшәү урыны буенча Яшел Үзән муниципаль районы Олы Карауҗа авыл җирлеге составына керүче Олы Карауҗа торак пунктында даими яшәүчеләр, Бөек Ватан сугышында катнашучылардан, 1 группа инвалидлардан, күп балалы гаиләләрдән , көндезге формада укучы студентлардан тыш, һәр 18 яше тулган кешедэн 500,00 сум күләмендә үзара салым кертү белән килешәсезме?, һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен түбәндәге эшләрне башкару буенча:

Вак таш сатып алу .

Халык җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:
Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында 494 кеше, тавыш бирүдә 281 кеше катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар кертелгән, бу 56,9% тәшкил итә.
Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:
халык җыенында катнашкан 281 кеше «РИЗА» позициясе өчен тавыш бирде;
"КАРШЫ" позициясе өчен тавыш бирмәделәр.

Бәян ителгәннәр нигезендә, халык җыены карар итте:
1.Яшел Үзән муниципаль районы составына керүче Олы Карауҗа авыл җирлегенең Олы Карауҗа торак пунктында халык җыены булып узды.
2. 2021 елда үзара салым акчасын яшәү урыны буенча теркәлгән һәм Яшел Үзән муниципаль районының Олы Карауҗа авыл җирлеге составына керүче Олы Карауҗа торак пунктында даими яшәүче, Бөек Ватан сугышында катнашучылардан, 1 төркем инвалидлардан, күп балалы гаиләләрдән, көндезге формада укучы студентлардан тыш, 18 яше тулган хэр кешедэн 500,00 сум күләмендә кертергә .
3.Алынган акчаларны җирле әһәмияткә ия булган мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару өчен: вак таш сатып алу.
4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында Яшел Үзән муниципаль районының рәсми сайтында урнаштыру юлы

белән бастырып чыгарырга. http://zelenodolsk.tatarstan.ru ("Интернет» челтәрендә) http://pravo.tatarstan.ru шулай ук Татарстан Республикасы, Яшел Үзән районы, Олы Карауҗа авылы, Күпер урамы, 23 нче йорт (мәдәният йорты бинасы), Олы Күлбаш авылы, Тау асты урамы, 26 нчы йорт (мәдәният йорты бинасы) адреслары буенча мәгълүмат стендларында.

5.Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында
рәислек итүче М. Р. Минһаҗев